КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 февраль г.Казань № 90

«Вознесение тракты. Җиңү проспектыннан М-7 «Идел» автомобиль юлына кадәр төзелеш участогы» төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлы участогыннан түләүле нигездә файдалану турында .

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясының 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Вознесение тракты. Җиңү проспектыннан М-7 «Идел» автомобиль юлына кадәр төзелеш участогы» төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлы участогыннан файдалануны 2048 елның 15 декабренә кадәр түләүле нигездә гамәлгә ашырырга .

2. Түләүле нигездә файдаланыла торган автомобиль юлы участогы түбәндәге техник характеристикаларга ия дип билгеләргә:

озынлыгы – 7,6 километр;

башлангыч пункт: Казан шәһәренең Җиңү проспекты;

соңгы пункт: Казан шәһәренең Совет районындагы һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районындагы М-7 «Идел» автомобиль юлы;

категориясе – 1А;

хәрәкәт полосасының киңлеге – 3,75 метр;

төп йөреш буенча хәрәкәт полосаларының гомуми саны – һәр якка 3 полоса;

хәрәкәтнең каршы юнәлешләрен аерып торучы үзәк бүлү полосасы – бөтен озынлыгы буена;

ясалма яктырту – бөтен озынлыгы буенча;

тимер юллар һәм трамвай юллары белән кисешү – юк;

башка автомобиль юллары һәм җәяүлеләр юллары белән кисешкән урыннар – юк;

башка автомобиль юлларына кушылган урыннар (керү/чыгу) исемлеге: М-7 «Идел» автомобиль юлы янәшәсендәге тоннель тибындагы юлүткәргеч, урнашу урыны – автомобиль юлының М-7 «Идел» белән автомобиль юлы кисешкән урыны, гомуми озынлыгы – 95,5 метр, тоннель өлешенең озынлыгы – 58,425 метр, машина юлы һәм тротуарларның габариты – 2 (Г – 9,4 + Т1 – 0,75 + Т2 – 1,5).

3. Транспорт чараларының альтернатив түләүсез йөрүен Казан шәһәренең Мамадыш тракты буенча башкарырга:

озынлыгы – 7,184 километр;

полосалар саны – 4 тән 6 га кадәр;

асфальт-бетон өслек мәйданы – 211 703 кв.метр.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин